ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4 статья. **Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:
а) ул вафат булганда;
б) үз вәкаләтләрен туктату турында язма гаризасы булганда;
в) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылганда;
г) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылганда яисә вафат булган дип игълан ителгәндә;
д) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә кергәндә;
е) ул Россия Федерациясе чикләреннән даими яшәү урынына чыгып киткәндә;
ж) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда;
з) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе

гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булганда;

и) депутат тиешле сайлауларда кандидат буларак теркәлгән чорда аңа карата Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу яисә аларның булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану фактлары билгеләнгәндә;

к) әлеге Законның 6 статьясындагы 4 пунктында, $7^1$ статьясындагы 4 – 6 пунктларында, $10^1$ статьясындагы 1 пунктында, $10^5$ статьясындагы 2, 4 – 6 пунктларында каралган таләпләр үтәлмәгәндә.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында каралган нигезләрдән тыш, депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны берничә мәртәбә үтәмәү тора. Әлеге җаваплылык чарасы әлеге Законның $10^3$ статьясында каралган тәртиптә Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан күрелә.

Коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны депутатның берничә мәртәбә үтәмәве дип депутат тарафыннан вәкаләтләр срогы дәвамында коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) бурычларны кимендә ике мәртәбә үтәмәү таныла.

3. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән йә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әлеге нигез барлыкка килү хакында мәгълүм булган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча, ә бу нигез Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышлары арасында барлыкка килсә, шушы нигез барлыкка килгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә. Әлеге статьяның 1 пунктындагы «ж» пунктчасында каралган очракта, депутатның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы законнарын кабул итүгә, шулай ук утырышта карарлар кабул итү юлы белән гамәлгә ашырыла торган башка конституциячел вәкаләтләрен башкаруга кагылышлы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән туктатыла.

4. Депутат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, барлыкка килгән вакантлы депутат мандатын биләү Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләрен билгели торган федераль законда һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

2) 6 статьяда:

а) 4 пунктта өченче җөмләне төшереп калдырырга;

б) $4^1$ пунктта «граждан» сүзен «граждан эше, административ эш» сүзләренә алмаштырырга;

3) $10^3$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ пункт өстәргә:

«$17^1$. Тикшерү нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны берничә мәртәбә үтәмәү ачыкланган очракта, тикшерү материаллары тикшерү нәтиҗәләрен карау көненнән алып өч эш көне эчендә Комиссия рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышына депутатның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату хакындагы мәсьәләне чыгару өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә җибәрелә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21. Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Президенты Администрациясе Җитәкчесе йә алар махсус вәкаләт биргән Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вазыйфаи заты карары буенча Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе билгеләнгән тәртиптә әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән тикшерүләрне гамәлгә ашырырга мөмкин. Мондый тикшерүләр Комиссия үткәрә торган тикшерүләрдән бәйсез рәвештә гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

4) $10^5$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$10^5$ статья. **Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр, тыюлар һәм бурычлар**

1. Депутат үз статусын депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле булмаган эшчәнлектә кулланырга хокуксыз.

2. Депутат үз вәкаләтләре срогы эчендә, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, Россия Федерациясе сенаторы, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, судья була алмый, Россия Федерациясенең башка дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектының башка дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, шулай ук муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын били алмый.

3. Депутат, коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән билгеләнә торган нигезләр булганда һәм тәртиптә, депутат вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү хакында Комиссиягә хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә җайга салу чараларын күрергә тиеш.

4. Депутат законда каралган тәртиптә затларның аны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итүнең барлык очраклары

турында тиешле мөрәҗәгать булган көннән алып биш көн эчендә Комиссиягә һәм прокуратура органнарына хәбәр итәргә тиеш.

5. Депутат, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган чит ил оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительләр һәм күзәтүчеләр советлары, башка органнары составына керергә хокуксыз.

6. Депутатка, аның иренә (хатынына) һәм балигъ булмаган балаларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела. «Чит ил финанс инструментлары» төшенчәсе коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәсендә кулланыла.

7. Депутат коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә һәм бурычларны башкарырга тиеш.

8. Депутат әлеге Законның 6 статьясындагы $4^1$ пунктында, әлеге статьяның 1 һәм 3 пунктларында каралган чикләүләрне, тыюларны бозган һәм бурычларны башкармаган, шулай ук керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән очракта, аңа карата түбәндәге җаваплылык чараларының берсе күрелергә мөмкин:

а) кисәтү;

б) депутатка карата җаваплылык чарасы күрү турында карар кабул ителү вакытыннан алып аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, депутат вәкаләтләрен туктатмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советында биләгән вазыйфасыннан азат итү;

в) вәкаләтләре срогы тәмамланганчы Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вазыйфалар биләүне тыю.

Депутатка карата санап кителгән җаваплылык чараларының берсен күрү турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары Комиссия үткәрә торган тикшерү нәтиҗәләрен һәм аның депутатка карата җаваплылык чараларының берсен күрү тәкъдимнәрен исәпкә алып кабул ителә.

Тикшерү әлеге Законның $10^3$ статьясында билгеләнгән нигезләрдә, тәртиптә һәм срокларда үткәрелә.

9. Әлеге статьяның 8 пунктында каралган нигезләр булганда, Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатка кисәтү ясарга тәкъдим итү;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатны, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, депутат вәкаләтләрен туктатмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советында биләгән вазыйфасыннан азат итәргә тәкъдим итү;

в) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатка аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вазыйфалар биләүне тыярга тәкъдим итү;

г) моның өчен җитәрлек нигезләр булганда башка дәлилләнгән карар.

Комиссиянең тиешле карары аны кабул итү көненнән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә җибәрелә.

10. Депутатка карата әлеге статьяның 8 пунктында санап кителгән җаваплылык чараларының берсен күрү турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары Комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча, ә карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттагы утырышларын уздыру арасындагы вакыт 30 көннән арткан чорда кабул ителгән булса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының якындагы утырышында, әмма Комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

11. Депутатка карата әлеге статьяның 8 пунктында каралган җаваплылык чарасын күрү турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

12. Депутатка карата кисәтү рәвешендә җаваплылык чарасын күрү турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми басмасында бастырып чыгарылырга һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

13. Җаваплылык чарасы күрелгәндә, депутат тарафыннан кылынган коррупциячел хокук бозуның характеры, аның авырлыгы, аны кылгандагы хәлләр, гаепнең дәрәҗәсе, депутатның башка чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәве һәм аның коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны башкаруы, шулай ук депутатның үз бурычларын үтәүнең алдагы нәтиҗәләре исәпкә алына.

Әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып бер ел дәвамында депутатка карата әлеге статья нигезендә яңадан җаваплылык чарасы күрелмәгән булса, ул җаваплылыкка тартылмаган булып санала.

14. Әлеге статьяның 8 пунктында каралган җаваплылык чаралары депутат тарафыннан хокук бозуны кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм аны кылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча күрелә.

15. Хокук бозуны һәм депутат тарафыннан бозылган норматив хокукый актларның нигезләмәләрен күрсәтеп, депутатка карата җаваплылык чарасын күрү турындагы яисә, дәлилләрне күрсәтеп, депутатка карата мондый җаваплылык чарасын күрүдән баш тарту хакындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары күчермәсе депутатка тиешле карарны чыгарган көннән алып өч эш көне эчендә имза куйдырып тапшырыла. Депутат әлеге карарга имза куеп танышудан баш тартса, тиешле акт төзелә.

16. Депутат законнар нигезендә аңа карата җаваплылык чарасы күрү турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына шикаять бирергә хокуклы.»;

5) $17^{1}$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$17^{1}$ статья. **Җинаять җаваплылыгына яисә административ җаваплылыкка тартылганда, җинаять-процессуаль яисә административ-процессуаль гамәлләр, оператив-эзләү чаралары башкарылганда депутатка гарантияләр**

1. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, депутатны җинаять җаваплылыгына яисә административ җаваплылыкка тарткан, аны тоткан, кулга алган, тентегән, аннан сорау алган, депутатка, аның багажына, шәхси һәм эш транспорты чараларына, хатларына, ул куллана торган элемтә чараларына һәм аныкы булган документларга карата башка җинаять-процессуаль яисә административ-процессуаль гамәлләр башкарылган, оператив-эзләү чаралары үткәрелгән очракта, шулай ук ул биләгән торак һәм хезмәт урыннарында оператив-эзләү чаралары үткәрелгәндә, җинаять эшләре яисә административ эшләр буенча эш алып баруның федераль законнарда билгеләнгән аерым тәртибе кулланыла.

2. Депутат әйтелгән фикере, тавыш бирүдә чагылдырган позициясе һәм депутат статусына туры килүче башка гамәлләре өчен җинаять җаваплылыгына яисә административ җаваплылыкка, шул исәптән аның вәкаләтләре срогы тәмамланганнан соң да, тартыла алмый. Әлеге нигезләмә депутат тарафыннан гавами мыскыллау, яла ягу яисә алар өчен федераль законда җаваплылык каралган башка хокук бозулар кылу очракларына кагылмый.

3. Депутат аңа үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә билгеле булган хәлләр турында граждан эше, административ эш яисә җинаять эше буенча шаһит күрсәтмәләре бирүдән баш тартырга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 108-ТРЗ